РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

«24» апрель 2018 ел № 152

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында» 2017 елның 13 декабрендәге 132 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы, «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 июнендәге 180-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктның 5 пунктчасының 1 абзацында «дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр» сүзтезмәсеннән соң «шулай ук» сүзен төшереп калдырырга;
- 16 пунктның 1 пунктчасының 2 абзацын бәян итәргә:

«Акционерлар җәмгыятьләренең идарә органнарында һәм ревизия комиссияләрендә, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләрдә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләре вәкилләре булып муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар, шулай ук башка затлар булырга мөмкин».

2. Әлеге карарны хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының икътисад сәясәте, бюджет һәм җирле үзидарә, Совет регламенты, хокук тәртибе, экология һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссияләренә йөкләргә.

Муниципаль район
башлыгы, Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин